| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КАРМАЛКА<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КАРМАЛКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

**«20» май 2021 ел** №14

Кармалка авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июлендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирләү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Лениногорск шәһәр прокурорының «Җирләү һәм җирләү эше турында» 2021 елның 29 мартындагы 02-08-02 номерлы федераль закон таләпләрен бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәсен карап, Кармалка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Кармалка авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июлендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирләү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяның 4 елешен 2 бүлекнең 2 елешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ир яисә хатынга, якын туганнарга, башка туганнарга, законлы вәкилгә яисә вафат булган, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү бурычын үз естенә алган башка затка күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш.

- җирләү ечен кирәкле документларны рәсмиләштерү (үлү турында медицина таныклыгы, үлү турында таныклык, Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге тарафыннан бирелгән таныклык) тиешле органнарга мерәҗәгать иткән кеннән бер тәүлек эчендә;

- җирләүне оештыруга һәм үткәрүгә заказны башкару, ул мәрхүмнең мәетенең кайсы моргта урнашуын, җирләү датасын һәм вакытын, матәм процессы маршрутын, кием-салым күләмен, мәрхүмнең буен, автокатафалка хезмәтенә заказны рәсмиләштерүне үз эченә ала;

- тыштан һәм эчтән тукыма белән тышланган агач табут тәкъдим итү;

-җирләү ечен кирәкле предметларны тәкъдим итү;

- йек теяү-бушату эшләрен дә кертеп, табут һәм кирәк-яракларны бер адреска китерү;

-гәүдәне табутка салу;

- җәсәдне зиратка һәм аннан соң күмелгән урынга илтү;

- кабер казу урынын билгеләүне, кышкы чорда кардан күмелгән урынны чистартуны, кул ысулы белән кабер казуны, су төбен чистартуны, кабер стенасын кулдан чистартуны үз эченә алган кабер урнаштыру;

- автокатафалкадан табутны чыгару һәм аны җирләү урынына җиткерү, матәм йоласы үткәрүне кетү, табут капкачын ябу, табутны кабер естенә төшерү (туфрак белән урнаны тешерү), каберне грунт белән күмү, кабер өстенә калкулык урнаштыруларны кертеп җирләү;

- кабердә язулы ритуаль теркәү билгесен (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм үлем датасы) урнаштыру.»;

2 бүлекнең 2 статьясын түбәндәге эчтәлектәге 5 часть белән тулыландырырга:

«5. Гражданнарны дин буенча күмүгә бәйле ритуаль хезмәтләр һәм җирләү ритуалы предметларының сыйфаты санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә, техник шартларга һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүгә һәм продукциягә мәҗбүри таләпләрне билгели торган башка хокукый актларга туры килергә тиеш, шулай ук, туганнары теләкләрен исәпкә алып, дин тоту кагыйдәләренә һәм тәртибенә туры килергә тиеш.»;

2 бүлекнең 2 статьясының 5, 6, 7, 8 частьларны 6, 7, 8, 9 частьлары дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва Кармалка авылы, Геодезия урамы, 38 А 2нче корылма (административ бина), Нагорная, 33 йорт ( авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, һәм әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карар халыкка игълан ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы О.В.Кириллова